ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

26 02 2024 г. № 191

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыннарны наемга алучыларның дәүләт яки муниципаль торак фонды торак урыныннан файдаланган өчен социаль найм һәм торак урыныннан файдаланган өчен найм түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясына яраклы рәвештә, Россия Федерациясе Төзелеш Министрлыгының һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номеры «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарны наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәреш кертү турында» боерыгына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыннарны наемга алучыларның дәүләт яки муниципаль торак фонды торак урыныннан файдаланган өчен социаль найм һәм торак урыныннан файдаланган өчен найм түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

нигезләмәнең 1 пунктының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынын наемга алу өчен түләү күләме 0,058 күләмендә, дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урынын наемга алу килешүе буенча бирелгән торак урынын наемга алу өчен 0,058 күләмендә билгеләнә».

2. Әлеге карар 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе Р.Ф. Булатов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874